ГЛАВА МАКУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.110, с. Макулово,
422582

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МАКЫЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 110 нче йорт, Макыл авылы,
422582

Тел.: (84379) 34-4-74, факс: (84379) 34-4-95.

06.11.2018 № 02

На №______________ от________________

**Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Клянчино авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56нчы маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче маддәсе нигезендә «Сез 2019нчы елда яшәү урыны буенча Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Клянчино авылы территориясендә теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән киләсе эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме» дигән мәсьәлә буенча 2018нче елның 6нчы ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

**- Клянчино авылында балалар мәйданчыгы төзү**

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашкан 144 кеше кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 78 кеше. Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 78 кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.
Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Клянчино авылында халык җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. "2019нчы елда Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең Клянчино авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ заттан 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме. Авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән билгеләнгән льготалы категория гражданнардан тыш, түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалар - Клянчино авылында балалар мәйданчыгы төзүгә тотыла" дигән мәсьәлә буенча карар кабул итәргә.

3. Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Клянчино авылы гражданнарының гражданнар җыены нәтиҗәләрен Макыл авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында танышып чыгу өчен игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче: А.И. Матвеева**